**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Урта Комар авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2022 елның 14 ноябре** **№3**

**«Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Югары Комар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 28 ноябренә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Югары Комар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Комар авылы, Мәктәп урамы, 17Б йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 28 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Югары Комар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Комар авылы, Мәктәп урамы, 17Б йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Урта Комар авыл җирлеге Югары Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, локаль сугышларда һәм Украинада махсус операция барышында һәлак булганнарның гаиләләреннән, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Комар авылы зираты өчен инструментларны саклау өчен будка (җиһазлар саклау каралтысы) төзү, ритуаль кирәк-яраклар инвентаре сатып алу. Проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Югары Комар авылы юл полотносын торгызу;
- тирәннән суырту насосы сатып алу һәм урнаштыру;
- су трассасын ремонтлау һәм тирәннән суырту насосын алыштыруга килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру. Проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; килешү буенча эшләр өчен түләү;

- Югары Комар авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм җәй көне территорияне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

5. Халык җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Урта Комар авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Комар авыл җирлеге башлыгы: Ю.И.Исынбаев.